## КАРАР

**“21” ноябрь 2023 ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар - Аты авыл җирлеге Утар-Аты авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә , 2023 елның 21 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

« Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Утар Аты авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү ,шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Совет урамы, Кооператив урамы, Комсомол урамы, Мәктәп урамы, Мәктәп урамыннан зиратка кадәр (300м) җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең йөрү өлешенең өслек һәм тигезләгеч катламнарын ясау өчен вак таш сатып алу;
- грейдер, каток хезмәтләре өчен түләү;
- юл-урам челтәрендә янмый торган ламочкаларны алыштыру өчен светодиодлы яктырткычлар сатып алу;
- торак пункт территориясендәге һәм Аты елгасы ярындагы агачларны һәм куакларны санитар кисү һәм чыгару;
- Аты елгасында вакытлыча плотина төзү буенча эшләр башкару , бульдозер, амкодор хезмәтләре өчен түләү?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”»

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 254 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 135 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 135 кеше тавыш бирде;

"Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар- Аты авыл җирлегендә Утар-Аты авылы халык җыенын узган һәм аның нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. « Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Утар – Аты авыл җирлеге Утар - Аты авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү ,шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Совет урамы, Кооператив урамы, Комсомол урамы, Мәктәп урамы, Мәктәп урамыннан зиратка кадәр (300м) җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең йөрү өлешенең өслек һәм тигезләгеч катламнарын ясау өчен вак таш сатып алу;

- грейдер, каток хезмәтләре өчен түләү;

-юл-урам челтәрендә янмый торган ламочкаларны алыштыру өчен светодиодлы яктырткычлар сатып алу;

-торак пункт территориясендәге һәм Аты елгасы ярындагы агачларны һәм куакларны санитар кисү һәм чыгару;

-Аты елгасында вакытлыча плотина төзү буенча эшләр башкару , бульдозер, амкодор хезмәтләре өчен түләү?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ» -135 "КАРШЫ"-0

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Утар Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева